Россия Федерациясе
мөселманнары Диния нәзарәте

Россия мөфтиләр Шурасы

بسم الله الرحمن الرحيم

# Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, Россия мөфтиләр Шурасы рәисе мөфти шәех Равил Гайнетдиннең Гыйд әл-Фитр — Ураза бәйрәме мөнәсәбәте белән мөрәҗәгатьнамәсе

**Мәскәү**
Һиҗри 1438 елның 1нче шәүвәле
Милади 2017 елның 25нче июне

# БИСМИЛЛӘҺИР-РАХМӘНИР-РАХИМ

Әлхәмдү лилләһи-ләзи җәгаләс-сыямә тәрбиятән лин-нуфуси вәл әбдән. Вәс-саләтү вәс-сәләмү аләә хәбибиһи вә расулиһил-ләзи хассәнә аләә таләбил-гуфран вә зыядәти зикрир-рахман, вә аләә әлиһи вә әсхабиһи әҗмәгыйн, вә аләә мән тәбигаһүм би ихсәнин иләә йәүмид-дин.

**Хөрмәтле дин кардәшләрем, газиз мөселманнар!**
**Әс-сәламү аләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ.**

Ерак-якыннардан иман өндәвен кабул итеп, Рамазан бәйрәмен үзем шикелле дин кардәшләрем белән бергә олы әҗер-саваплы гыйбадәт сафларында уздырыйм дип Аллаһның йорты — бәйтуллаһка килгән газиз иман әһеле сезгә һәм безгә Раббыбызның бетмәс рәхмәтләре, бәрәкәтләре һәм ике дөньяда да сәламе җөмләбезгә насыйп булып, бу кадерле йортта изге гыйбадәт кылып, хисапсыз әҗерләргә ирешергә һәм мөбарәк Ураза гаете савабыннан өлешләнергә насыйп булса иде!

Гыйд әл-Фитр — Ураза гаете уңаеннан сезләргә ихлас тәбрик-котлауларымны җиткерәм, галәмнәрне Яратучы, Мәрхәмәтле Раббыбызга барчабызның да рамазан аенда тоткан уразаларыбыз, кылган намаз вә догаларыбыз, биргән зәкәт һәм садакаларыбыз, изге гамәлләребез кабуллардан булса иде дип догалар кылып калам.

Калебләрне рухи паклау һәм яңарту ае булган бу рамазан айларын озату моңсу булса да, әлеге ай дәвамында ирешкән рухи күтәренкелек, калебләрнең сафлануы һәммәбезгә шатлык вә ләззәт китерә.

مَنْ صَامَ رَمَضَانَ إِيمَانًا وَاحْتِسَابًا غُفِرَ لَهُ مَا تَقَدَّمَ مِنْ ذَنْبِهِ

*«Кем дә кем рамазан аенда чын күңелдән ышану һәм өмет белән ураза тотса, шул кешенең элек кылган гөнаһлары кичерелер»* («Сахих» Бохари, Мөслим), — сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу аләйһи вә сәллам хәдисендә җиткергән бу изге хәбәргә ихластан ышанып, шуңа өметләр баглыйбыз.

Бер айлык рухи иҗтиһадның нәтиҗәләрен барлаганда, шунысын истә тотыйк: аңлы рәвештә, мөкамиллеккә омтылып кылынган гыйбадәтләрнең билгесе булып рамазан ае тәмамлангач та шушы рухи халәтне өзмичә, Аллаһуга гыйбадәт кылуны, җәмгыятькә игелек китерүне дәвам иттерү торыр.

Пәйгамбәребез салләллаһу аләйһи вә сәллам хәдисендә болай ди:

أَحَبَّ الْأَعْمَالِ إِلَى اللَّهِ أَدْوَمُهَا وَإِنْ قَلَّ

*«Аллаһ каршында иң хупланган гамәлләр — кечкенә булсалар да, дәвамлы булучыларыдыр»*
(«Сахих» Бохари).

لَا تَحْقِرَنَّ مِنَ الْمَعْرُوفِ شَيْئًا، وَلَوْ أَنْ
تَلْقَى أَخَاكَ بِوَجْهٍ طَلْقٍ

*«Изге гамәлләрнең иң вакларын да кире какмагыз, хәтта бу игелек кардәшегезгә ягымлы, дустанә караш белән күз ату булса да»*
(«Сахих» Мөслим).

Рамазан аеның рухи эчтәлге күп төрле, шул исәптән иң әһәмиятле якларыннан — адәм җанында киң күңеллелек, шәфкатьлелек хисләрен тергезеп җибәрү. Бу миһербанлылык сыйфатларын без рамазан ае тәмамланганнан соң да сакларга тырышырга тиеш. Рамазан дәвамында дусларыбызны, күршеләребезне ифтарларга чакырып, диненә һәм милләтенә карамый рамазан чатырларында меңнәрчә кешене кунак итеп, мохтаҗларга зәкәт үл-фитр — фитра садакаларыбызны тапшырып, шуңа инандык: киң күңеллелек, юмартлык алар мәшәкать түгел, бәлки киресенчә, бәрәкәткә, рухи канәгатьләнүгә китерүче сыйфатлар. Шушы ирешелгән рухи байлыкны югалтмыйча, Аллаһының ризалыгын алу өчен игелекле гамәлләребезне дәвамлы итү бик мөһим.

Аллаһының соңгы Расүле салләллаһу аләйһи вә сәллам әйткән:

أَحَبُّ النَّاسِ إِلَى اللَّهِ أَنْفَعُهُمْ لِلنَّاسِ

*«Аллаһ каршында иң сөекле бәндәләре – кешеләргә игелек китерүчеләр».*

اتَّقُوا النَّارَ وَلَوْ بِشِقِّ تَمْرَةٍ، فَإِنْ لَمْ تَجِدْ فَبِكَلِمَةٍ طَيِّبَةٍ

*«Кем Җәһәннәм утыннан хөрмә җимешенең яртысы белән булса да саклана ала, шуны эшләсен. Анысы да табылмаса, һичьюгында җылы сүзе белән дә мөмкин».*

Һичшиксез игелек, юмартлык, ярдәмчел булу — болар мөэминнең сыйфатлары, тар күңеллелек исә иманның зәгыйфлегеннән килә. Коръәни Кәримдә Аллаһы Тәгалә әйтә:

أَرَأَيْتَ الَّذِى يُكَذِّبُ بِالدِّينِ فَذَٰلِكَ الَّذِى يَدُعُّ الْيَتِيمَ وَلَا يَحُضُّ عَلَىٰ طَعَامِ الْمِسْكِينِ

***«Динне ялган дип танучыны күрдеме? Ул – ятимне дорфа итеп куып җибәрүче, үзен дә, башкаларны да мохтаҗларны, мескеннәрне тукландырырга өндәмәүче»*** (107: 1–3).

Пәйгамбәребез салләллаһу аләйһи вә сәлламнең шундый хәдисе дә билгеле:

السَّخِيُّ قَرِيبٌ مِنَ اللَّهِ قَرِيبٌ مِنَ الْجَنَّةِ قَرِيبٌ مِنَ النَّاسِ
بَعِيدٌ مِنَ النَّارِ، وَالْبَخِيلُ بَعِيدٌ مِنَ اللَّهِ بَعِيدٌ

مِنَ الجَنَّةِ بَعِيدٌ مِنَ النَّاسِ قَرِيبٌ

مِنَ النَّارِ، وَالجَاهِلُ السَّخِيُّ أَحَبُّ إِلَى اللَّهِ عَزَّ

وَجَلَّ مِنْ عَابِدٍ بَخِيلٍ

*«Юмарт кеше Аллаһыга да, кешеләргә дә, Җәннәткә дә якын. Җәһәннәмнән ул ерак. Саран кеше Аллаһыга да, кешеләргә дә, Җәннәткә дә якын булмас. Ләкин Җәһәннәмгә якын булыр. Юмарт кеше надан булса да, Аллаһ каршында диндардыр. Ул гыйбадәт кылучы саран кешедән сөеклерәктер»*

(«Сөнән» Тирмизи).

Сүземне тәмамлап, Аллаһыдан һәрбарчабызга рамазан ае пакълыгын һәм тәкъвалыгын дәвам итеп, киләчәк гаетләрне дә саулыкта вә иминлектә каршыларга насыйп итсә иде, һәммәбезгә Аллаһыдан иман байлыгы, игелек һәм шәфкать, миһербанлык, Ватаныбызга, халкыбызга тынычлык һәм чәчәк ату, барча инсаниятькә иминлек сорап догада калам.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Һәр кайсыбызга да тоткан уразаларыбыз, намаз-гыйбәдәтләребез, тәравих тәкъбирләре, ифтар мәҗлесләре күңелләребездә иң матур тәэсирләр калдырып, тәннәребезгә шифа биреп, калебләребезгә нур салып, иманнарыбызны ныгытып, тормышларыбызга ләззәтле ямь бирсен иде. Раббыбыз Сөбханәһү вә Тәгалә һәркайсыбызга да саулык исәнлектә, ил-көн тынычлыгында олы рамазан аеыбызны уздырып, күбрәк яхшы гамәлләр кылып яшәргә, ураза тотып безләрне гөнаһлардан араласа иде, һәркайсыбызга да көч һәм куәтен бирсә иде! Йә Аллам! Уразалар тотып олы дәрәҗәләргә ирешергә, начар фикерләрдән, бозык эшләрдән ерак торырга, иманнарыбызны гыйбадәтең белән көчәйтергә, мөшәррәф айларыбызда йортларыбызны Коръән нуры белән тутырырга Үзең насыйп вә мияссәр әйләсәң иде! Киләчәк елларыбызда да һәркайсыбызга да саулык-сәламәтлектә, ил-көн тынычлыгында шушындый изге айларга, көннәргә, шатлыклы минут һәм мизгелләргә ирешергә Аллаһ Раббыбыз насыйп әйләсә иде! Илебезгә тынычлык, хөкүмәт башлыкларыбызга хәер зиһен, сабырлык теләп калам!

**Гает бәйрәмнәребез мөбарәк булсын!**
**Вәс-сәләму алейкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһ!**

***Мөфти шәех Равил Гайнетдин,***

*Россия Федерациясе мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,*
*Россия мөфтиләр шурасы рәисе,*
*Россия Федерациясе Президенты каршындагы Дини оешмалар белән хезмәттәшлек буенча Совет әгъзасы*